РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«26» август 2022г. с. Тюлячи № 153

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» бәяләү дәрәҗәсенә кергән күрсәткечләрне хисап чорына җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлегенең регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 19 июнендәге 18-6309 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» бәяләү дәрәҗәсенә кергән күрсәткечләрне хисап чорына җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлегенең регламентын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» 08 2022 № 153
карарына кушымта

**Татарстан Республикасының «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» буенча Теләче муниципаль районы югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең федераль күрсәткеченең Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» ярдәмче күрсәткечләрен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлегенең регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Татарстан Республикасының «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» буенча Теләче муниципаль районы югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең федераль күрсәткеченең Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» ярдәмче күрсәткечләрен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлегенең регламенты (алга таба - Регламент) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында» 2022 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 4 июнендәге 1024 номерлы карары,«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләве тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнелгән һәм Татарстан Республикасының «Әйләнә-тирә мохит сыйфаты» буенча Теләче муниципаль районы югары вазыйфаи заты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең федераль күрсәткеченең Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны, мең кеше» ярдәмче күрсәткечләре әһәмиятләрен җыю тәртибен билгели.

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларын үткәрүне координацияләүче булып тора. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләнгән тәртиптә урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү буенча чараларда катнашучыларның куркынычсызлыгын һәм оештыру чараларын тәэмин итә.

Теләче муниципаль районында Ярдәмче күрсәткечнең әһәмиятләрен мониторинглауда җаваплылык үзеге булып Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

Теләче муниципаль районында «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» ДКУ, Теләче муниципаль районы чикләрендә урнашкан «Саба урманчылыгы» ДКУ (алга таба - «Урманчылык» ДКУ) Ярдәмче күрсәткечнең әһәмиятләрен җыйган өчен җаваплылык үзеге булып тора.

Ярдәмче күрсәткечнең әһәмиятләре турында мәгълүмат җиткерүчеләр булып юридик һәм физик затлар - табигатьне саклау чараларында катнашучылар тора. Ярдәмче күрсәткечнең әһәмиятләре турында мәгълүмат бирү рәвеше Регламентка кушымтага туры килергә тиеш. Алына торган һәм тапшырыла торган мәгълүмат «Урманчылык» ДКУ җитәкче-урманчысы боерыгы белән билгеләнгән җаваплы зат тарафыннан архивлана.

«Урманчылык» ДКУ муниципаль районы буенча берләштерелгән мәгълүматы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына каты күчермәдә яисә электрон рәвештә җибәрелә.

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты, ведомствоара электрон документлар әйләнеше мәгълүмати системасын кулланып, берләштерелгән мәгълүматны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына (алга таба - Министрлык) җибәрә.

## II. Аңлатмалар аппараты

Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре кулланыла.

- Урманнарны яңадан җитештерү - урман фонды территориясендә яңа урман утыртмалары булдыру һәм формалаштыру чаралары.
- Урман үрчетү - элек урман утыртмалары белән мәшгуль булмаган җирләрдә яңа урман утыртмалары булдыру чарасы.
- Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык - физик затлар һәм/яки юридик затлар, алар агач утыртуда һәм башка табигатьне саклау акцияләрендә катнашалар.
- Инициатив мәгълүмат - урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларында катнашучы яисә катнашырга планлаштыручы инициатив төркем тарафыннан тапшырыла торган мәгълүмат.

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм формалары

Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чаралары түбәндәгечә үткәрелергә мөмкин:

- алдан әзерләнгән план буенча урманнарны яңадан торгызу һәм урман үрчетү чараларын оешкан рәвештә яисә югарырак хакимият органнары һәм/яисә оешмаларның гамәлгә куючылары, коммерция оешмаларының идарә органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нигезендә оператив тәртиптә уздыру рәвешендә;

- иҗтимагый оешмалар, социаль учреждениеләр, җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, торак пунктларда яшәүчеләрнең инициативалы төркемнәре, предприятиеләр һәм оешмалар үткәрә торган инициатив тәртиптә.

Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларының беренче категориясе урман фонды территориясендә уздырыла. Кагыйдә буларак, бу урманчылар билгеләгән урыннарда агач утырту чаралары. Яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларын үткәрү планы (алга таба - План) Министрлык тарафыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы белән килештерелә. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты яңадан җитештерү һәм урман үрчетү буенча Планга туры килә торган чаралар үткәрү графигын төзи һәм күрсәтелгән график нигезендә чараларда катнашучыларны чакыра.

Чараларның икенче категориясе - Теләче муниципаль районы территориясендә урманнарны яңадан торгызу һәм урман үрчетү чаралары. Мондый чаралар мониторингы формализацияләнмәгән, ә алар биләгән халык саны шактый зур булганга, санап үтелгән субъектлар өчен мөлкәт, мәгълүмат, кадрлар, финанс формалары рәвешендәге дәүләт һәм/яисә муниципаль ярдәм чаралары каралырга мөмкин. Мондый чаралар исемлеге республика яисә муниципаль дәрәҗәдәге хакимиятнең тиешле органы тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта җирле дәрәҗәдәге чаралар йә Теләче муниципаль районы бюджетында, йә муниципаль дәрәҗәдәге программаларда һәм проектларда каралган чаралар составында карала.

Шулай итеп, чараларның беренче категориясе буенча мәгълүмат Кушымта нигезендә билгеләнгән вакыт аралыгында хисап формасы буенча тапшырыла. Икенче категория чаралары буенча мәгълүмат Кушымтада каралганча формада чара үткәрүгә рөхсәт алганда тапшырыла, чара үткәрелгәннән соң мәгълүмат шул ук форма буенча, ләкин инде хисап рәвешендә килә.

Мәгълүмат Теләче муниципаль районы территориясендә электрон рәвештә яисә каты күчермәдә «Урманчылык» ДКУ мәгълүматын җыю өчен җаваплылык үзәгенә тапшырыла. Җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты Кушымтаның формасы буенча исәпкә алу журналы алып бара. Каты күчермәгә кергән һәм электрон рәвештә килгән формалар мәгълүматы ведомствоара электрон документлар әйләнеше мәгълүмати системасын кулланып белешмәләр базасына кертелә, ведомствоара электрон документ әйләнеше мәгълүмати системасын кулланып ____ көн _________ ай ______ Министрлыкка җибәрелә, ведомствоара электрон документлар әйләнешенең мәгълүмат системасын кулланып, 5 ел дәвамында муниципаль электрон исәпкә алу журналында саклана.

Кушымта

**Урманнарны яңадан җитештерү һәм урман үрчетү чараларына җәлеп ителгән халык саны буенча күрсәткечләрне мониторинглау рәвеше**

| План | | | | | | | | | Факт | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № | Чарада катнашучы (оешма/физик зат) | Урманчылык | Адресы | Чараны уздыру датасы | Мәйданы (га) | Утыртылган агачлар саны (мең данә) | Төре | Катнашучылар саны | № | Чарада катнашучы (оешма/физик зат) | Урманчылык | Адресы | Чараны уздыру датасы | Мәйданы (га) | Утыртылган агачлар саны (мең данә) | Төре | Катнашучылар саны |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |

*Искәрмә:* Министрлык адресына тапшырыла торган мәгълүмат (мәгълүматлар) эчтәлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 4 июнендәге 1024 номерлы «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында» 2022 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карарына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» карары нигезендә билгеләнә.